Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Карамышевская ООШ им. Бари Габдрахманова» Черемшанского муниципального района Республики Татарстан

| «Рассмотрено» | «Согласовано» | «Утверждаю» |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО учителей начальных классов ___ Шайхулова З.М. Протокол №1 от «20» августа 2021г. | Заместитель директора по ВР ___ Юнусова Ф.Х. «31» августа 2021г. | Директор МБОУ « Карамышевская ООШ им. Бари Габдрахманова»: ___ Якупова Г.Ф. Приказ №78 от «31» августа 2021г. |

Рабочая программа по внеурочной деятельности

«Этикет уңышка юл»

для 1-4 классов

Составитель программы: учитель начальных классов 1 квалификационной категории

МБОУ « Карамышевская ООШ им. Бари Габдрахманова»

Гайфуллина Гульфина Минсагировна

# Этикет-уңышка юл

**Эчтәлек**

Аңлатма язуы...................... ……………………………………………………. 3

«Этикет – уңышка юл” программасының эчтәлеге. 1 нче сыйныф..............… 8

Тематик планлаштыру. 1 нче сыйныф.....……………………………………… ..10

«Этикет – уңышка юл” программасының эчтәлеге. 2 нче сыйныф.......... …. .12

Тематик планлаштыру. 2 нче сыйныф.....……………………………………… ..15

«Этикет – уңышка юл” программасының эчтәлеге. 3 нче сыйныф.......... ….. 17

Тематик планлаштыру. 3 нче сыйныф.....……………………………………… ..20

«Этикет – уңышка юл” программасының эчтәлеге. 4 нче сыйныф …......….. 22

Тематик планлаштыру. 4 нче сыйныф.....……………………………………... 25

Йомгаклау. Ирешелгән нәтиҗәләр......................................................................27

Кулланылган әдәбият исемлеге ..……………………………………………… 29

Өстәмәләр.........………………………………………………………………… 31

Әхлакый тәрбиялелекнең диагностикасы..................................................31

Әти-әниләр өчен анкета.................................................................................33

Укучылар өчен анкета....................................................................................35

Әти-әниләр өчен үткәрелгән анкета сораулары.................................. ..36

## Аңлатма язуы.

Шәхеснең камилләшү һәм үсүендә әхлак тәрбиясенең ролен педагогика элек-электән исбатлап, раслап килгән. Әхлак ул – кешенең эш-хәрәкәтләрендә, көндәлек тормышында билгеле бер калыпка салынган, билгеле бер кыйммәтләрдән торган сыйфат. Мәктәпнең уку-укыту системасына нинди генә үзгәрешләр кертелсә дә, яшь буынга әхлак, патриотик һәм рухи тәрбия бирү иң актуаль мәсьәлә булып кала. Шәхес үсешендә һәм формалашуында әхлак тәрбиясенең никадәр мөһим булуы педагогикада борынгы заманнардан ук танылган. **Ян Коменский** "Гадәтләр кулланмасы" дигән хезмәтендә борынгы рим философы Сенеканың түбәндәге фикерен китерә: **"Иң башта яхшы гадәтләргә өйрән, аннары – зирәклеккә, беренчесеннән башка икенчесен өйрәнү авыр.**

Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Көндәшлеккә сәләтле, заман шартларына яраклашкан, рухи һәм физик яктан камил булган иҗади шәхес тәрбияләү – иң төп максатыбыз. Ә ул туган илен, телен яратучы, үз милләтенең тарихын, мәдәниятын, гореф-гадәтләрен, күркәм йолаларын хөрмәт итүче булырга тиеш.

Шуңа да бүгенге көндә Россия белем бирү системасының төп максаты булып тирән белемле укучылар тәрбияләп үстерү генә түгел, ә бар яктан да камил шәхес тәрбияләү тора. Укучы шәхесе педагогиканың игътибар үзәгенә куела. Бу максатны тормышка ашыру өчен баланы һәрьяклап үстерүгә юнәлдерелгән "Дәрестән тыш эшчәнлек" бүлеген үз эченә алган яңа буын Федераль дәүләт стандарты булдырылды.

Балага рухи-әхлакый үсеш һәм тәрбия бирүнең төп документаль нигезен Россия Федерациясенең "Белем бирү" турындагы Законы, Стандарт, Россия гражданинына рухи-әхлакый үсеш һәм тәрбия бирү Концепциясе тәшкил итә. **Стандартта** мондый юллар бар: **"Гомуми белем бирүнең башлангыч баскычында рухи-әхлакый яктан үстерү һәм тәрбия бирүнең төп максаты булып Ватан язмышын үз язмышы итеп кабул итүче, үз иленең бүгенгесе һәм киләчәге өчен җаваплылыгын аңлаучы, күпмилләтле Россия Федерациясе халыкларының рухи һәм мәдәни гореф-гадәтләре үрнәгендә тәрбияләнгән югары әхлаклы, иҗади, белемле Россия гражданины тәрбияләү тора."**

Стандарт таләпләренә туры китереп, рухи-әхлакый үсеш һәм тәрбия бирү Прогарммасы һәм Концепция, башлангыч гомуми белем бирүнең барлык бүлекләрен формалаштыруда төп юнәлеш булып тора.

Мәктәптә әхлак тәрбиясенең нигезе укучыда әхлак сыйфатлары булдыруның киң планлы юнәлешенә нигезләнә. Әлеге юнәлеш укучы балада җәмгыятькә, кешеләргә, хезмәткә һәм укучының үз-үзенә әхлакый мөнәсәбәт тәрбияләүне үз эченә ала.

Укучы балада әхлак сыйфатлары тәрбияләүнең эчтәлегенә кергән төшенчәләрне бәяләгәндә иң элек шуны истә тотарга кирәк: шәхесне һәрьяклап

камилләштерү барышында әлеге эчтәлекнең һәрбер төшенчәсе үзара бәйләнештә тәэсир итә һәм бер-берсенә үзгәреш-төзәтмәләр кертә.

Әхлаклылык принциплары һәм тәртип кагыйдәләре шәхескә карата булган тышкы таләпләр системасы булып тора. Әлеге принциплар һәм кагыйдәләр билгеле бер шәхеснең яшәү рәвеше, әхлаклылык нормасы булып әверелсен өчен, иң беренче чиратта аларны шәхес үзе инанып кабул итәргә, үзенең эш-хәрәкәтләрендә, максатларында шул принциплар һәм шул кагыйдәләргә йөз тотарга тиеш.

Әхлак тәрбиясенең нигезе һәм бурычлары – тәрбия процессы – кешенең тулысынча шәхес буларак формалашуы. Ләкин шушы тулы бер процесста төп һәм иң әһәмиятле урынны әхлак тәрбиясе били. Әхлак тәрбиясе – тәрбия эше системасының үзәге, иң мөһим юнәлеше. Кеше үз эшчәнлеге дәвамында, аралашу вакытында дөньяга, кешеләргә мөнәсәбәттә әхлак нигезләрен туплый.

Әхлак тәрбиясе процессы укучы баланың һәртөрле эшчәнлегенә үтеп керә, аның дөньяга карашында, кешеләр белән үзара мөнәсәбәтендә чагыла, аның шәхесендәге төп чалымнарны били.

Мәктәптә әхлак тәрбиясенең төп бурычлары укучы балада әхлак тәҗрибәсе тудырудан тора. Яхшыны – яманнан, яманны яхшыдан аера белү тәҗрибәсе кешедә яшьтән үк тәрбияләнә. Ул аны көндәлек тормышы, эше, эшчәнлеге, башкаларга мөнәсәбәте белән ныгыта гына бара. Бала чакта барлыкка килгән әхлак нормалары кешене җитлеккән, олыгайган чорына кадәр озата бара. Беренче сыйныфта ук бала әхлак тәрбиясенең асылы белән таныша: “**Аз сөйлә күбрәк тыңларга өйрән; тыңлаучан, тыныч һәм тыйнак бул. Уеңа килгәннең барысын да сөйләмә; ләкин нәрсә сөйлисең турында алдан уйла. Дөресен белмисең икән, раслама һәм дәгъвалама. Бурычка алгансың икән, кире кайтар; вәгъдә биргәнсең икән, үтә; бушка кабул итеп алгансың икән, рәхмәтеңне әйт**.” “**Гаиләдә без – ул мин һәм минем туганнарым. Безнең һәрберебез өчен иң мөһиме – гаиләдә мәхәббәт һәм бер береңә хөрмәт, үзара аңлашып һәм ярдәмләшеп яшәү**.”

Курсның актуальлеге һәм социаль әһәмияте шунда – ул үсеп баручы яшь буынга кешеләр арасында үзара дөрес мөнәсәбәтләр урнаштыруны аңлап, үз-үзеңне тәрбияләү һәм үсеш юлларын эзләүгә юнәлтелгән. Курс иҗади процесска укучыларны, әти-әниләрне, укытучы һәм тәрбиячеләрне катнаштыруны күз алдында тота.

Бирелгән курсның практик әһәмияте шунда – әйләнә-тирә чынбарлыкка дөрес караш укытучы һәм укучының уртак эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә, ә әхлаклылык нормалары 1 нче сыйныфтан “үстерелә” башлый.

«Этика – уңышка юл” курсы мәктәпнең укыту һәм тәрбия мәсьәләсенең кирәкле һәм аерылгысыз бер өлеше булып тора. Бары тик рухи-әхлакый яктан камил шәхес кенә җәмгыятьтә үз урынын табып, гаиләсе, дуслары, башка кешеләр белән дөрес мөгамәлә урнаштырып, тормышта уңышка ирешә алачак.

**Программаның максаты:**

укучыларның дөньяга, кешеләргә, үз-үзләренә карата әхлакый нормаларны үзләштерүе.

**Программаның бурычлары:**

- балаларны җәмгыятьтәге әхлак кагыйдәләре, әхлак нормалары белән таныштыру, даими рәвештә хәбәрдар булуларына ирешү;

- балаларда әхлак төшенчәсе турында уңай тәҗрибә булуына ирешү;
- балаларның хисләрендә, аңында, тәртибендә әхлаклылык принципларына омтылыш тәрбияләү;
- укучыларда өзлексез танып белүгә омтылыш тәрбияләү, һәркем үзенең әдәплелек дәрәҗәсен күтәрә алуына ышаныч тудыру;
- ирекле, һәрьяклап камил шәхеснең әхлакый идеалын балаларның тулысынча күзаллавына, шуңа омтылуына ирешү.

Программа 1-4 нче сыйныф укучыларына этика һәм этикет өлкәсендә иң мөһим кагыйдәләр белән танышырга һәм тормышта кулланырга мөмкинлек бирә.

Программа 4 бүлектән тора:

1. Аралашу этикасы.
1. Этикет.
2. Әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтнең этик нормалары.
3. Коллективта үзара мөнәсәбәт этикасы.

Укытуның төп методы – уен. Теоретик характердагы барлык информация балалар теманың сорауларына үзләре җаваплар эзләп табарлык уен формасында, я таблица-плакатлар белән эш формасында бирелә. Балалар үзләштерергә тиешле күнекмәләр рольле уеннар аркылы ныгытыла.

## Эшчәнлек төрләре һәм формалары

- уен;
- танып белү;
- туган якны өйрәнү;
- сюжетлы уеннар;
- мультфильмнар карау;
- китапханәләргә йөрү;
- мәктәп музеена керү;
- кинолар карау.

## Үткәрү урыны

- мәктәп
- авыл урамы;
- мәктәп музее.
-

## Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлек программасын үзләштерүе буенча көтелгән нәтиҗәләр

Дәрестән тыш эшчәнлек программасын үзләштерү буенча түбәндәге нәтиҗәләр көтелә:

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- укучылар мораль нормалар һәм үз-үзеңне әхлаклы тоту кагыйдәләрен, гаилә әгъзалары, өлкән буын вәкилләре арасында булырга тиешле этик нормаларны белергә тиешләр;
- укучылар этика грамматикасын һәм әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашуның этик нормаларны өйрәнүгә позитив карашлы булырга тиешләр;
- укучыларның сыйныфташларына карата мөгамәләсе дустанә, этик нормаларга туры килерлек булырга тиеш;
- укучылар иптәшләре, дуслары, сыйныфташлары, гаилә әгъзалары белән аралашып, этик нормаларны практикада ныгытырга тиешләр;
- мәктәптән тыш төрле сфера вәкилләре белән үз-үзләрен тота, дөрес әңгәмә кора һәм аралаша белергә тиешләр.

**Тәрбияви нәтиҗәләр:**

- үз-үзеңне әхлаклы тоту һәм мораль нормалар турында беренчел күзаллау;
- яшьтәшләре, үзләреннән кечкенәләр, өлкәннәр белән әхлак кагыйдәләренә туры килерлек итеп аралашу;
- башка кешеләрнең килеп чыккан проблемаларына читтән карамау, кыен хәлдә калган кешеләргә кайгыртучанлык күрсәтү;
- үз кылган гамәлләрең өчен җавап бирә, анализ ясый, әйләнә-тирәдәге начар гамәлләрне күрә һәм анализлый белү;
- әти-әниләргә, өлкәннәргә, үзеңнән кечеләргә кайгыртучан булу;
- гаиләңнең, үзең укыган белем йортының традицияләрен белү, аларны хөрмәтләү һәм саклау.

**Көтелгән нәтиҗәләрне исәпкә алу формасы:**

1. Сорау.
2. Күзәтү.
3. Диагностика:
   - әхлакый яктан үз-үзеңне бәяләү;
   - үз-үзеңне тоту этикасы;
   - яшәү байлыкларына караш;

- әхлакый мотивация.

4. Әти-әниләр һәм балалар арасында анкета үткәрү.

Түбәндәге дәрестән тыш эшчәнлек программасы “Бари Габдрахманов исемендәге Кармыш төп мәктәбе ” “Башлангыч сыйныфларда этик программа”сына башлангыч гомумбелем бирүнең Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп, мәктәпнең укыту планының “Дәрестән тыш эшчәнлек” бүлегенә туры китереп төзелде. Программа ,башлангыч сыйныф укучылары өчен елга 33 сәгать исәбеннән тәкъдим ителә.

Үткәрү вакыты – атнага 1 сәгать.

Программа башлангыч сыйныф укытучылары тарафыннан тормышка ашырыла.

## «Этикет – уңышка юл программасының” эчтәлеге

### 1 нче бүлек. Аралашу этикасы (8 сәгать)

1 нче тема. Яхшы сүз, якты көн кебек.
Яраткан әкиятләр. «Яхшы сүз, якты көн кебек» мәкале. Тылсымлы сүзләр. «Тылсымлы чәчәк» уены.

2 нче тема. Итәгатьлелек серләре.
Итәгатьлелек турында әңгәмә. «Итәгатьле - итәгатьсез» уены. «Вежливый кролик» - мексика әкияте. Л.Н.Толстойның «Тиен һәм бүре» әкияте.

3 нче тема . Яшәсен исле сабын.
“Серле дустым-будильник” уены. Көндәлек режим турында әңгәмә. Шәхси гигиена. Рәсем конкурсы.

4 нче тема. Авыл урамнары буйлап.
Авыл урамнарында үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре. Кешене хөрмәт итү күнекмәләре. Әхлак тәрбиясе кагыйдәләреннән дөрес куллану.

5 нче тема. Үз-үзеңне өйрәнү.
Әкияткә сәяхәт: кечкенә аланчыкта, күл буенда, тылсымлы диңгез дөньясында.

6 нчы тема . Үзең эшләгән эшкә җавап бирә бел.
В.Осеева - «Кто наказал его?». Әңгәмә. «Тылсымлы чәчәк» уены.

7 нче тема. Коллективка бүләгем.
Сюрприз-дәрес. Уеннар.

8 нче тема. Кушамат тагу – әдәпсезлек.

### 2 нче бүлек. Этикет (8 сәгать)

9 нче тема. Әхлак тәрбиясенең гади кагыйдәләре.
Әхлак тәрбиясе кагыйдәләре. Этикет кагыйдәләренең тарихы.

10 нчы тема. Көндәлек этика нормалары.
С. Михалковның «Одна рифма», А. Бартоның «Почему телефон занят» әсәрләре. «Ярый-ярамый» уены.

11 нчы тема. Яхшы тонның күңелле кагыйдәләре.
В.Маяковскийның “Нәрсә ул яхшы, нәрсә ул начар?”әсәре белән танышу.

12 нче тема. Этикет турында әкият.
«Яраткан ризыклар» һәм аларны дөрес куллану.

13 нче тема. Этикет турында әкиятнең дәвамы.
Балалар рәсемнәреннән күргәзмә оештыру. Әңгәмә “Без табын янында утырганда нинди хаталарга юл куябыз?”

14 нче тема. Этикет иленә сәяхәт.
Табын янында үзеңне дөрес тоту.

15 -16 нче темалар. “Рәхим итегез”.
Табын янына чакыру. Яңа ел бәйрәме.

**3 нче бүлек. Әйләнә - тирәдәгеләр белән аралашуның этика нормалары (9 сәгать)**

17 нче тема. Тылсымлы әкияткә сәяхәт.
Әхлак тәрбиясенең алтын кагыйдәләре.
18 нче тема. Мин тылсымчы булсам.
Өлешләп мәкаль җыю. «Чәчәк таҗы» уены.
19 нчы тема. Кечкенә генә эш зур ялкаулыктан яхшырак.
«Тере» картина төзү.
20 нче тема. "Авылымның үткәне һәм бүгенгесе".
Авылым тарихы. Туган як турында шигырьләр, җырлар.
21нче тема. Һәр халыкның –үз геройлары.
Рәсемнәр күргәзмәсе. Төрле халык әйтемнәре.
22 нче тема. Уйныйбыз да җырлыйбыз.
Төрле халык уеннары, җырлары.
23 нче тема. Минем яраткан әнием.
Әниләр турында шигырьләр сөйләү.
24 нче тема. Сөекле әниләребезгә багышлап.
Балалар концерты. Рәсемнәр күргәзмәсе.
25 нче тема. Табигатьне ярату.
Табигать турында шигырьләр, җырлар.

**4 нче бүлек. Коллективта аралашу этикасы (9 сәгать)**

26 нчы тема. Сөенечне уртаклаша белү.
Төп кагыйдә «Кешегә хөрмәт күрсәтсәң, үзеңне дә хөрмәт итәрләр».
27 нче тема. Минем сыйныф – минем дусларым.
Әңгәмә «Безнең яхшы якларыбыз» һәм «Безнең тискәре якларыбыз».
28 нче тема. Үзен генә яратучы – бар кешегә дә сөйкемсез.
«Светофор» уены. В. Осеева - «Долг».
29 нчы тема. Уйный-уйный уйлыйк әле.
«Букет җыю» уены. Җырлар җырлау.
30 нчы тема. Малайлар һәм кызлар дуслыгы турында.
Е. Пермяк - «Ышанычлы кеше».
31 нче тема. Изге уйлар иленә сәяхәт.
Изге уйлар-эшләр кагыйдәләрен төзү.
32-34 нче темалар. Мәрхәмәтлелек кояшка тиң.
Йомгаклау дәресе. Уеннар, җырлар.

**Тематик планлаштыру**

**1нче сыйныф**

| № | Тема | Сәгать саны | Эшчәнлек төре. | |
|---|---|---|---|---|
| **Аралашу этикасы (8 сәгать)** | | | | |
| 1 | Яхшы сүз якты көн кебек. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. | |
| 2 | Итәгатьлелек серләре. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. | |
| 3 | Яшәсен исле сабын. | 1 | Уеннар. Конкурслар. Рәсемнәр. Танып-белү әңгәмәсе. Рольле уеннар. Авыл урамнарында практик дәрес. | |
| 4 | Авыл урамнары буйлап. | 1 | | |
| 5 | Үз-үзеңне өйрәнү. | 1 | Әкияткә сәяхәт. Конкурслар. | |
| 6 | Үзең эшләгән эшкә җавап бирә бел. | 1 | Хикәя уку. Әңгәмә, уеннар. | |
| 7 | Коллективка - бүләгем. | 1 | Сюрприз-дәрес. Уеннар. | |
| 8 | Кушамат тагу –әдәпсезлек. | 1 | Инсценировка. | |
| **Этикет (8 сәгать)** | | | | |
| 9 | Әхлак тәрбиясенең гади кагыйдәләре. | 1 | Әңгәмә. | |
| 10 | Көндәлек этика нормалары. | 1 | Сорауларга җавап. Уеннар. | |
| 11 | Яхшы тонның күңелле кагыйдәләре. | 1 | Әңгәмә. Картиналар белән эш. | |
| 12 | Этикет турында әкият. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. | |
| 13 | Этикет турында әкиятнең дәвамы. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. | |
| 14 | Этикет иленә сәяхәт. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. Китапханәгә бару. | |
| 15-16 | “Рәхим итегез!” Табын янына чакыру. | 2 | Танып-белү әңгәмәсе. Рольле уеннар. Мәктәп ашханәсендә практик дәрес. | |
| **Әйләнә -тирәдәгеләр белән аралашуның этика нормалары (9 сәгать)** | | | | |
| 17 | Тылсымлы әкият иленә сәяхәт. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар.конкурслар. | |
| 18 | Мин тылсымчы булсам. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. | |
| 19 | Кечкенә генә эш зур ялкаулыктан яхшырак. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. Сәхнәләштерү. Төркемнәрдә эш. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20 | Туган авылымның үткәне һәм бүгенгесе . | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. Мәктәп музеенда булу. |
| 21 | Һәр халыкның – үз герое. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Мәктәп музеенда булу. |
| 22 | Уйныйбыз да җырлыйбыз. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. |
| 23 | Минем яраткан әнием. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. |
| 24 | Сөекле әниләребезгә багышлап. | 1 | Бәйрәм оештыру. |
| 25 | Табигатьне ярату. | 1 | Болынга бару. Әңгәмә. |
| **Коллективта аралашу этикасы (8 сәгать)** | | | |
| 26 | Сөенечне уртаклаша белү. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. Төркемнәрдә эшләү. |
| 27 | Минем сыйныф- минем дусларым. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. |
| 28 | Үзен генә яратучы-бар кешегә дә сөйкемсез. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар. Уен-сәяхәт. |
| 29 | Уйный-уйный уйлыйк әле. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Саф һавада уеннар. |
| 30 | Малайлар һәм кызлар дуслыгы турында. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уеннар, конкурслар. |
| 31 | Изге уйлар иленә сәяхәт. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уен нар. Мультфильм карау. |
| 32-33 | Мәрхәмәтлелек кояшка тиң. | 2 | Бәйрәм оештыру. |

**«Этикет – уңышка юл" программасының эчтәлеге**

**2 нче сыйныф**

**1 нче бүлек . Аралашу этикеты (7 сәгать)**

1 нче тема. Җыр белән күңелле.

Әдәплелек турында сөйләшү. Тәрбияле булуны ничек аңларга? Елмаю һәрнәрсәне җылыта.

2 нче тема. Җир йөзендә мәрхәмәтле булып яшәү шатлыгы.

Мәрхәмәтлелек һәм кыюлык турында сөйләшү. Дусларның Гудвинга сәяхәте турында рәсем конкурсы.

3 нче тема. Яхшылык эшләү – үзеңне сөендерү.

Күргәзмәләр залына читтән торып сәяхәт. Яхшылык турында рәсемнәр конкурсы.

4 нче тема. Башкалар турында уйла.

Яхшылык, кылган яхшылыклар турында әңгәмә. Әкиятләрдән өзекләр уку. «Үзең теләгәнчә эшлә, сиңа карата да шулай эшләсеннәр» кагыйдәсен ачыклау.

5 нче тема. Коллективка бүләк.

Сюрприз-дәрес, әңгәмә дәрес.

6 нчы тема. Эш беткәч уйнарга ярый.

Мәкальне аңлату: «Эш беткәч, уйнарга ярый». Әдәплелек значогы ясау. Төркемнәрдә эш.

7 нче тема. Башка кешедә сиңа нәрсә ошамый, ул эшне үзең дә эшләмә.

Әдәплелек значокларын мәктәп күргәзмәсенә кую. Яхшылык кылу һәм тигез хокуклылык турында сөйләшү. Тылсымлы кагыйдәне ятлау : «Башка кешедә сиңа нәрсә ошамый, ул эшне үзең дә эшләмә».

**2 нче бүлек . Этикет (8 сәгать)**

8 нче тема. Этикет кагыйдәләре буенча.

Әңгәмә: «Нәрсә ул этикет?» Лабиринт буенча этикет кагыйдәләренә сәяхәт. Культуралы тәртипкә мәсьәләләр чишү. Мәкальләрне аңлату. «Кешене хөрмәт итү – үзеңне хөрмәтләү».

9 нчы тема . Өстәл янына чакыру.

Этикет иленә сәяхәт. Өстәл артында практик дәрес. Әкият геройларын сәхнәләштерү. «Туган көне булганнар өчен концерт» уены.

10 нчы тема. Без яши торган йорт ,мәктәп.

Этикет очракларын «Экзамен» формасында тикшерү. Этикет кагыйдәләрен ачыклау.

11 нче тема. Без кибеткә барабыз.

Кибеттә этикет кагыйдәләре. Төрле очракларны уйнау.

12 нче тема. Юллар, транспорт, җәяүлеләр юлы.

«Светофор» уены. Юл йөрү кагыйдәләре буенча практик дәрес.

13 – 14 нче темалар. Болын, урман, елга – ял итү урыннары.

Урман аланына сәяхәт. Болында, урманда, елга буенда үзеңне тоту кагыйдәләре .

15 нче тема. Кыш бабайда кунакта.

Яңа ел бәйрәме.

**3 нче бүлек. Янәшәдәгеләр белән аралашу этикасы (9 сәгать)**

16 нчы тема. Башкага шатлык бүләк ит.

“Чыршы тирәли әйлән-бәйлән» уен программасы. Җөмлә төзү «Башкага шатлык бүләк ит». «Кемгә ничек без шатлык бүләк итә алабыз» темасына әңгәмә.

17 нче тема. Кәеф нәрсәгә бәйле.

Әңгәмә «Кәеф нәрсәгә бәйле». Яхшы кәеф тудыру кагыйдәләре белән танышу.

18 нче тема. Үз мәрхәмәтлелегегездән оялмагыз.

Гномикка һәм Урманчы-картка бүләк. Газета чыгару

19 нчы тема. Минем өем – минем гаиләм .

« Гномик Пыхка һәм Урмачы-картка нинди йорт төзергә» темасына бәхәс.

20 нче тема. Кеше хезмәттә матурлана.

Практик дәрес: «Безнең гомуми йортыбыз».

21 нче тема. Җирдә барыбыз да кояш балалары.

Урмачы-карт һәм гномик Пых аланына сәяхәт. С. Маршакның «Унике ай» экияте.

22 нче тема. Әниләребезне котлыйбыз.

Бәйрәм формасындагы дәрес. Әниләргә концерт. Рәсемнәр һәм кул эшләре күргәзмәсе.

23 нче тема. Өлкәннәр һәм яшьтәшләр белән.

Фотокүргәзмә - «Минем иң яхшы дустым». «Мин кемне үземнең иң яхшы дустым дип саныйм» темасына әңгәмә. Яхшылык турында киңәш-мәкальләр. Дуска яхшы киңәш.

24 нче тема. Башкаларның ышанычын акла.

«Янәшәдәгеләр белән мөгаләмә этикасы» темасына йомгаклау дәресе. Гномик Пыхка һәм Урмачы-картка хат.

**Коллективта аралашу этикасы (8 сәгать)**

25 нче тема. Барыбыз да бергә җыелгач нинди яхшы.

Әңгәмә «Каникулларны ничек үткәрдегез». Бөтен коллективның төсле кәеф язмасы. “Кәефне ничек күтәреп була?” әңгәмә. Җыр «Чын дус».

26 нчы тема. Бер-беребезгә киңәш бирәбез.

Уен. Тылсымлы көзге белән сөйләшү: « Минем тылсымлы көзгем, дөресен генә әйт әле, минем дусларым миңа нинди киңәш бирерләр икән?»

27 нче тема. Кызлар һәм малайлар өчен махсус һәм гомуми киңәшмә. Сыйныф коллективына таләпләр. Бу киңәшмәгә җаваплы кешеләрне сайлау.

28 нче тема. Минем белән кем дә булса сөйләшсә иде.

Этикет бабайга сәяхәт. Үзеңнең сөйләмеңне төзүгә практик дәрес.

29 нчы тема. Язгы урман буйлап сәяхәт.

Урманга экскурсия вакытында урманда үзеңне тоту кагыйдәләре.

30 нчы тема. Коллективка бүләк.

Коллективта һәр бала үзен күрсәтерлек эшчәнлек. Үзеңнең акылыңны, белемеңне, талантыңны бүләк иткәндә коллективыңны уйла.

31 нче тема. Газета ясыйбыз.

«Этик грамматикасы” курсының еллык эше турында әңгәмә. Балалар үзләренең тәкъдимнәрен, киңәшләрен газетага бирәләр. Газетаны матурлыйлар.

32-33 нче темалар. Мәрхәмәтлелек кояшка тиң.

Йомгаклау дәресе. Уеннар. Җырлар. Таҗ яфракчыклары җыю.
Әти-әниләр өчен бәйрәм үткәрү.

## Тематик планлаштыру

## 2 нче сыйныф

| № | Тема | Сәгатьләр саны | Эшчәнлек төре |
|---|---|---|---|
| **Аралашу этикасы (8 сәгать)** | | | |
| 1 | Җырлап яшәү күңелле. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уен. |
| 2 | Җирдә мәрхәмәтле булып яшәү куаныч. | 1 | Әкияткә сәяхәт. Рәсемнәр конкурсы. |
| 3 | Яхшылык эшләү – үзеңне куандыру. | 1 | Күргәзмә залын карарга керү. Рәсемнәр. |
| 4 | Башкалар турында уйла. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Әкиятләрдән өзекләр уку. Сәхнәләштерү. |
| 5 | Коллективка бүләк. | 1 | Сюрприз-дәрес. Уеннар. |
| 6 | Эш беткәч уйнарга ярый. | 1 | Мәкальләр белән эш. Практик эш. Төркемнәрдә эш. |
| 7-8 | Башкада яратмаганны үзеңдә эшләмә. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уен. |
| **Этикет (8 сәгать)** | | | |
| 9 | Этикет кагыйдәләре буенча. | 1 | Әңгәмә. Лабиринт буйлап этикет кагыйдәләренә сәяхәт. Мәсьәләләр чишү. Сәхнәләштерү. |
| 10 | Өстәл янына чакыру. | 1 | Практик дәрес. Төрле очракларны күрсәтү. Уен. |
| 11 | Без яши торган мәктәп, йорт. | 1 | Миниатюр-сәхнә. |
| 12 | Кая барабыз? Менә кибет. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Төрле очракларны күрсәтү. Кибеткә керү. |
| 13 | Юллар, транспорт, җәяүлеләр юлы | 1 | Танып-белү. |
| 14-15 | Урман, елга, болын – кайда ял итәргә була. | 2 | Урман аланына сәяхәт. |
| 16 | Кыш бабайда кунакта. | 1 | Бәйрәм. |
| **Әйләнә тирәдәгеләр белән аралашу этикасы нормалары (9 сәгать)** | | | |
| 17 | Башкага шатлык бүләк ит. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уен. |
| 18 | Кәеф нәрсәгә бәйле. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уен. |
| 19 | Үзегезнең мәрхәмәтлелегегездән оялмагыз. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уен. |
| 20 | Минем йортым- минем гаиләм | 1 | Дискуссия. |
| 21 | Кеше эштә яхшыра | 1 | Практик дәрес. |
| 22 | Җирдә барыбыз да кояш балалары | 1 | Әкияткә сәяхәт. Мультфильм |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | карау. |
| 23 | Әниләребезне котлыйк | 1 | Бәйрәм. Рәсемнәр. |
| 24 | Өлкәннәр һәм яшьтәшләр белән | 1 | Танып- белү әңгәмәсе. Уен. Мәкальләр белән эш. |
| 25 | Башкаларның ышанычын акла | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Балалар утравына сәяхәт. |
| **Коллективта аралашу этикасы (9 сәгать)** | | | |
| 26 | Барыбыз да бергә җыелгач нинди яхшы. | 1 | Танып- белү әңгәмәсе. Уен. |
| 27 | Бер-беребезгә киңәш бирәбез. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Әкиятләрдән өзекләр карау. |
| 28 | Кызлар һәм малайлар өчен махсус һәм гомуми киңәшмә. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уен. |
| 29 | Минем белән кем дә булса сөйләшсен иде. | 1 | Язгы паркка экскурсия. Практик эш. |
| 30 | Язгы урманга сәяхәт. | 1 | Экскурсия. |
| 31 | Коллективка бүләк. | 1 | Дәрес – сюрприз. |
| 32 | Газета ясыйбыз. | 1 | Танып-белү әңгәмәсе. Уен. |
| 33-34 | Мәрхәмәтлелек кояшка тиң. | 1 | Бәйрәм. |

**«Этикет – уңышка юл” программасының эчтәлеге**

**3 нче сыйныф**

**1 нче бүлек. Аралашу этикасы (8 сәгать)**

1 нче тема. Барыгыз да исәнмесез!

«Исәнмесез!» Бу сүз нәрсәне аңлата? Бу һәркемгә бары тик яхшылык теләү. Димәк, очрашуны яхшылык теләүдән, елмаюдан башлыйк.

2 нче тема. Бер-беребезне саклыйк!

Мәрхәмәтле Фея белән очрашу. Усал Фея хакимлек иткән ил бар. Ул: “Кешеләр берсен-берсе сакламаска тиеш”-ди. Бу илдә барысы да аяныч. Мәрхәмәтле Фея әдәпле, игътибарлы, ихтирамлы, рәхмәтле булырга өйрәтә.

3 нче тема. Яхшы сүзләр белән дуслашыйк.

Сүзләрне “бозып сөйләү” эше бара. Саранлык-юмартлык белән, көнчелек – яхшылык, мәрхәмәтлелек белән алмашына. Тупаслык – ягымлылык, иркәлек, кечелеклелек белән. Кансызлык – кызгану белән һ. б.

4 нче тема. Яхшы эшләрне яратабыз.

Әйләнәбездә яхшылыклар гына күрергә өйрәнәбез. Мәче Леопольдның яхшы эшләр турындагы җырларын өйрәнү. Яхшы эшләр һәм мәрхәмәтле сүзләрне бер чылбырга берләштерү.

5 нче тема. Иглекле эшеңне, мәрхәмәтле сүзеңне бүләк ит.

Сыйныфтан читләшкән, яратып бетермәгән иптәшләре турында балаларның фикерләре. Аның эшләгән яхшы эшләрен күрсәтү. Укытучының өстәмә сүзләре. Бу сүзләрне балаларга истәлек өчен магнитофон тасмасына яздыру.

6 нчы тема. Аралаша беләбез.

Үзеңә һәм янәшәңдәгеләргә әйбәт булсын өчен аерым кагыйдәләрне истән чыгармаска кирәк. Алар арасында иң кирәклесе – башка кешегә хөрмәт белән карау: аның кәефен күрә белү, аңа таяныч булу, башкаларның теләге белән килешү, юл бирү.

7 нче тема. Һәрберсе кызыклы.

Балалар чиратта торучыга аның кызыклы якларын әйтәләр. Кирәк дип тапканда укытучы өстәмәләр кертә. Сыйныфта һәркемнең кызыклы яклары булганда нинди кызык һәм бөтен кешегә яхшы икәнен билгеләү.

8 нче тема. Коллективка бүләк.

Аралашу бәйрәме үткәрелә: һәркем коллективка бүләк әзерли: уйлап чыгарылган нәрсә, җыр, хикәя.

**2 нче бүлек. Этикет (7 сәгать)**

9 нчы тема. Этикет бабайның зирәклеге.

Этикет – кеше тормышындагы төрле очраклы хәлләрдә кешенең үз-үзен тоту кагыйдәләре җыелмасы. Кешеләр арасында лаеклы яшәү өчен зирәклекне аңлау.

10 нчы тема. Этикет бабай белән өстәл артында.

Бергәләп чәй эчү. Өстәл артында төрле очракларны уйнап күрсәтү.

11 нче тема. Мәктәпнең этикет кагыйдәләре.

Чишенү бүлмәсендә, сыйныф белән очрашуда,ашханәдә үз-үзеңне тотуда, дәрестә кагыйдәләрне куллану.

12 нче тема. Янәшәңдә кешеләр күп булганда.

Урамда, кибеттә, транспортта, театрда, музейда, китапханәдә барлык җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре кабатлана.

13 нче тема. Гаиләдәге проблемаларны ничек чишәргә?
Гаиләдә балаларны дулкынландырган хәлләр турында әңгәмә. Гаиләдә талашулар, кычкырулар булмасын, өйдә рәхәт булсын өчен нишләргә?

14 нче тема. Сезнең сөйләмегез чишмәдәй матур.
Укучыларның “учак” янынында матур итеп сөйләшүләре. Аларның сөйләмендә бернинди каршылыклар да булырга тиеш түгел. Сөйләм тулы сулы елгага ошап торсын.

15 нче тема. Яңа елны каршылыйбыз.
Өстәл янында сыйныф ”учакчыгы”.

**3 нче бүлек. Янәшәдәгеләр белән этик аралашу (10 сәгать)**

16 нчы тема. Рух – ул безнең җан иясе.
Әкият геройларын аерылып торган сыйфатларына карап рәсемгә төшерү. Фикер алышу: ”Мин нинди очракларда елыйм...”, “Кайчан көләм..., ”Кайчан шатланам...”

17 нче тема. Яхшылык һәм ышанычлылыкның тылсымлы капкаларын ачыгыз.
Рухи көчләр ялгыз калмас өчен тормыштагы төрле очраклы хәлләрне үзгәртергә мөмкин. Яхшылык дөньяны матурлый, аны төрлеләндерә. Күңелләрнең тылсымлы ишекләре – алар яхшылык һәм ышаныч ишекләре.

18 нче тема. Яхшы җырлар яхшылыкка илтә.
Балалар күпчелек сайлаган җырларны җырлыйлар. Җырдагы яраткан геройларны сурәтлиләр. Рәсемнәр күргәзмәсе.

19 нчы тема. Үзеңә кара һәм башкалар белән чагыштыр.
Кеше турында уйлану. Без барыбыз да төрле. Һәрберебезнең дөньяга карашы да төрле. Үзебезгә һәм башкаларга карап, без яхшылык һәм начарлык турында уйланабыз.

20 нче тема. Үзеңне аңларга булыш.
Бер-берсен ачу өчен балалар кара-каршы сөйләшәләр: кайда яши, вакытын кем белән үткәрә, гаиләсе нинди, өйдә нәрсә эшләргә ярата, нәрсә яратмый һ.б.

21 нче тема. Чын-чыннан һәм ясалма.
Чынлык – ул тормыштагы чынбарлык. Ул безнең сиземләүләребезгә, кылган эшләребезгә, тормышыбызга тәэсир итә. Бу җанлы әйберләр генә түгел: кеше, хайваннар, табигать, безнең әйләнә-тирәгә мөнәсәбәтебезне белдерүче төшенчәләр.

22 нче тема. Туган йорт җылысы..
Гаиләдә, еш җыелып, булган проблемаларны хәл итәбезме? Өйдәге җылылык һәр гаилә кешесен җылытырга тиеш.

23 нче тема. Әниләребезне котлыйбыз.
Бәйрәм дәрес. Бәйрәмгә әниләр, әбиләр, апалар чакырыла. Аларга бүләкләр бирелә. Рәсемнәр конкурсы. ”Минем әниемнең, әбиемнең, апамның сурәте”.

24 нче тема. Чәчәкләр, чәчәкләр – аларда Ватаным җаны.
Чәчәкләр – алар җанлы гәүдәләнеш, Ватан чакыруы, безне туган җиргә бәйләүче тере җепләр.

25 нче тема. Сиңа кояш елмайганда.
Йомгаклау дәресе – яз һәм җырлар бәйрәме.

**Коллективка караш  этикасы (9 сәгать)**

26 нчы тема. Коллектив белән бергә булырга.

Шарт кую: коллективтагы бөтен начарлыкны җиңәргә. Бу эштә һәркем үз юлын сайлый, һәркем үзенә бирем бирә. Шатлыгы да бергә.

27 нче тема . Коллектив миннән башлана.

Төрле характерлы булып, бер коллективта ничек яшәргә? Нәрсәне яхшы, нәрсәне начар дип санарга. Сине хөрмәт итсеннәр өчен син үзеңдә нинди сыйфатлар булдырырга тиеш.?

28 нче тема.  Коллективка бүләк.

Дәрес традицион методика буенча үткәрелә.

29 нчы тема. Кызлар һәм малайларга серле киңәшләр.

Малайлар һәм кызларга аерым сораулыклар, серле карточкалар тутыру. Фикерләшкәндә гомумиләштерелә.

30 нчы тема. Үзеңә үзең әйт.

Һәркем үзенең кайсы ягыннан канәгать, кайсы ягыннан юк һәм ни өчен икәнен  яза. Киләчәккә биремнәр.Теләккә ничек ирешергә.

31 нче тема.  Менә без дә акыллы һәм мәрхәмәтле була башладык.

Лабиринт буйлап безгә ярдәм иткән, яхшы гамәлләр күрсәткән  зирәк киңәшләр артыннан сәяхәт.

32-34 нче тема. Мәктәпкә багышлана.

Этика юнәлешләре буенча йомгаклау бәйрәмнәре.

**Тематик планлаштыру**

**3 нче сыйныф**

| № | Тема | Сәгатьләр саны | Эшчәнлек төре |
|---|---|---|---|
| **Аралашу этикасы (8 сәгать)** | | | |
| 1 | Барыгыз да исәнмесез! | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 2 | Бер беребезне саклыйк. | 1 | Әкияткә сәяхәт. Театральләштерү. Педагогик мәсьәләләр чишү. |
| 3 | Яхшы сүзләр белән дуслашабыз. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен |
| 4 | Яхшы эшләрне яратабыз. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Җырлар өйрәнү. |
| 5 | Яхшылык һәм тәмле сүз бүләк ит. | 1 | Әкият иленә сәяхәт. |
| 6 | Аралаша беләбез. | 1 | Хикәя. Әңгәмә. Уен. |
| 7 | Һәркем үзенчә кызыклы. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 8 | Коллективка бүләк. | 1 | Сюрприз-дәрес. Уеннар. |
| **Этикет (7 сәгать)** | | | |
| 9 | Этикет бабайның зирәклеге. | 1 | Әнгәмә. Мәсьәләләр чишү. |
| 10 | Этикет бабай белән өстәл артында. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 11 | Мәктәп этикеты кагыйдәләре. | 1 | Рәсемнәр белән эш. Сәхнәләштерү. |
| 12 | Янәшәдә күп кешеләр булганда. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. Шәһәр буйлап экскурсия. |
| 13 | Гаилә проблемаларын ничек хәл итәргә. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 14 | Безнең сөйләмебезнең чиста чишмәсе. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 15 | Яңа елны каршылыйбыз. | 1 | Сыйныфта Яңа ел кичәсе. |
| **Әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашуның этик нормалары (10 сәгать)** | | | |
| 16 | Күнел – безнең эш җимешебез. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. Әкият геройларын ясау. |
| 17 | Киң күңеллелек һәм ышачның ишекләрен ачыгыз. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 18 | Яхшы җырлар мәрхәмәтлеккә өйрәтә. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Рәсем ясау. Рәсемнәр күргәзмәсе. Театрга поход. |
| 19 | Үзеңә кара һәм башкалар белән чагыштыр. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 20 | Үзеңне аңларга ярдәм ит. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 21 | Чынбарлык һәм ясалмалылык | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында. | | |
| 22 | Туган йорт җылысы. | 1 | Рәсемнәр күргәзмәсе. Сочинение «Минем өем”. |
| 23 | Без әниләребезне котлыйбыз. | 1 | Әниләр бәйрәме. |
| 24 | Чәчәкләр, чәчәкләр – сездә Туган ил рухы. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Авыл урамнары буенча сәяхәт. |
| 25 | Сиңа кояш көлгәндә. | 1 | Бәйрәм. Уеннар. Җырлар. |
| **Коллективта аралашу этикасы. 9 сәгать** | | | |
| 26 | Коллектив булыр өчен. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 27 | Коллектив миннән башлана. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 28 | Коллективка бүләк. | 1 | Дәрес - сюрприз. Уен. |
| 29 | Малайларга һәм кызларга серле киңәшләр. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен |
| 30 | Үзеңә үзең әйт. | 1 | Сочинение “Үзеңә үзең әйт”. |
| 31 | Менә без дә акыллы һәм мәрхәмәтле була башладык. | 1 | “Мәрхәмәтлелек иле буйлап сәяхәт”. Уеннар. |
| 32-34 | Мәктәбебезгә багышлана. | 3 | Әти-әниләр өчен бәйрәм кичәсе. |

## «Этикет – уңышка юл” программасының эчтәлеге

## 4 нче сыйныф

### 1 нче бүлек.  Аралашу этикасы. (7 сәгать)

1 нче тема. Тирә-ягыңа игътибар белән кара.
Кешенең горурлык, тыйнаклык, яхшылык сыйфатларын чагылдырган берничә педагогик мәсьләләрне чишү. Кешенең шәхес буларак формалашуында, үз-үзен тотышында, характерында төрле әхлакый нормаларның чагылыш табуын ачыклау.

2 нче тема.  Үз-үзең була белү осталыгы.
Намус тәрбияләү авыр, ә ялганлау җиңел.

3 нче тема. Гражданинга нәрсә лаек.
Гражданин, гражданлык, гражданлык активлыгы кебек төшенчәләрнең мәгънәсенә төшенү. Мәктәп, сыйныф тормышында үз роленне билгеләү, башкаларны да шатландыру өчен нәрсә дә булса эшләү – һәр гражданның намус эше.

4 нче тема. Хезмәт эш көннәрендә дә бәйрәм ясый ала.
Хезмәт кешене тәрбияли, ә җимешләре аның тормышын бизи. Шуңа да: “Хезмәт булмаган җирдә, бакчалар үсмиләр”, - диләр. Хезмәт ул физик эш кенә түгел. Карандаш тотып китап өстендә дә эшлиләр...Үз-үзеңне тәрбияләү – шулай ук зур хезмәт.

5 нче тема. Мәктәп вальсы бәйрәме.
Девиз: «Синга бәйрәм ясаганнарын көтмә, ә бәйрәмне үзең яса!» Вальсның мәктәп тормышындагы роле.

6 – 7 нче темалар. Көзге янына чакыру.
Көзгегә бирелгән тылысымлы сорауны бөтен кеше дә белә: “Яле, көзгем, сөйләп бир, тик дөресен генә әйт...”. «Үзең нинди, көзгең шундый”.

### 2 нче бүлек. Этикет (8  сәгать)

8 нче тема. Сабыр төбе – сары алтын.
Этикетның тарихы белән танышу. Этикетның нормалары  - кешенең үз-үзен тотышындагы иң күркәм сыйфатларның җыелмасы ул.

9 – 10 нче тема. Синең үз-үзеңне тоту стиле.
Кешенең үз-үзен тотышында нинди сыйфатлар булырга, ә нindiләре булмаска тиеш.  Әдәплелек турындагы мәкальләр белән эш. Коллективта үзара аралашу кагыйдәләре уйлап чыгару.

11 нче тема. Малайлар. Кызлар.
Кызлар һәм малайлар өчен үз-үзеңне тоту буенча этикет кагыйдәләрен анализлау. Укучыларның үзләре уйлап тапкан киңәшләрен рольләп уйнап карау.

12 нче тема. Уйныйбыз һәм уйлыйбыз.

Чит кешенең фотографиясенә карап, аның турында фикерләреңне белдерү. Балаларны һәр кешегә карата дустанә мөнәсәбәт кирәклегенә төшендерү. Рольле уеннар.

13 нче тема. Кайчан нинди сүз әйтергә.

Сөйләшә белү зур осталык сорый. Һәр кеше үзенең сөйләгән сүзе өчен җаваплы. Әдәпсез сүз – кешенең сәламәтлегенә зур зыян, ул кешене бик тирән җәрәхәтли, кешеләр арасындагы гауганың, талашның башы булып тора.

14 нче тема. Уртак өстәл артында.

Бәйрәм табынын әзерләү, өстәл артында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Бергәләп өстәл әзерләү. Этикет кагыйдәләрен ныгыту.

15 нче тема. Киң күңелллелек һәм яхшылык.

Киң күңелллелек һәм яхшылык кешеләргә бирелгән иң күркәм сыйфатлар. Аларны үзеңдә тәрбиялә һәм кешеләргә яхшылык кыл.

## 3 нче бүлек. Әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашуның этик нормалары (10 сәгать)

16 нче тема. «Яхшылык кылырга ашык» (халык хикмәте).

Уен моментлары. Ролле уеннар. Яхшылык турында мәкальләр, әйтемнәр, хикмәтле сүзләр. Кешенең яратылышы – яхшылык кылу. «Җир кешеләре, уйлагыз, фикерләгез, яхшылык кылыгыз!” чакыруы.

17 нче тема. «Яхшы уйла, һәм фикерләрең яхшы гамәлләргә әйләнер» (Л.Н. Толстой)

Тормышта төрле ситуацияләр килеп чыга, аннан дөрес чыгу юлларын таба белегез. Үзеңнең иң яхшы кешелек сыйфатларыңны яклый бел. Начарлыкка, хаксызлыкка каршы тору, явызлыкка җәза бирү - зур кыюлык сораучы яхшы гамәлдер. Начарлыкка каршы тора бел!

18 нче тема. Әти-әни йорты.

Рольле уеннар. Гаиләдә ялкаулыкны. тотнаксызлыкны, тупаслыкны ничек тыеп калырга. Көндәлек йөкләмәләр – кешенең бурычын тәшкил итүче тамчылар алар.

19 нче тема. Үз әниләрегезне яратыгыз.

“Әнинең күзләре нидән моңсу? Безнең әниләрнең моңсу минутлары, сагыш-моңнарын ничек кыскартырга” анкетасы.

20 нче тема. «Без әниләребезне котлыйбыз».

Әниләргә багышланган «Әнием – иң якыным» бәйрәме.

21 нче тема. Йөрәген кешеләргә бирүчеләр турында.

Иң чиста, иң якты ярату – ул әниләрне, Туган илне ярату. Кешелек хакына үз-үзләрен корбан итүчеләр турында.

22 нче тема. Юмарт була бел.

“Ярату” һәм “юмартлык” арасындагы аермаларны билгеләү. Ярату һәм башкалар турында кайгырту – кешелек юмартлыгының төп нигезе.

23 нче тема. Рәхмәт белдерү бәйрәме.

Барлык балаларның бәйрәмдә катнашуы, үз тәкъдимнәрен кертүе.

24 нче тема. Кеше яхшы эшләре белән мактаулы.

Хикмәтле сүзләр белән эшләү. Үз-үзеңне аңлау өчен анкета үткәрү.

## 4 нче бүлек. Коллективта аралашу этикасы. (9 сәгать)

25 нче тема. Миңа минем турыда сөйлә.
Башкаларга карата үз фикереңне дөрес, кешене үпкәләтмәслек формада җиткерә белү.

26 нче тема. Бер-берегезгә иътибар белән карагыз.
Аучы турындагы әкияттән чыгып, бер кеше бөтен кеше өчен, бөтен кеше бер кеше өчен яшәгән коллективта ышанычлы, шатлыклы һәм җиңел.

27 нче тема. Коллективка бүләк.
Балаларның бер-берсенә мөнәсәбәтен билгеләү өчен коллектив эшчәнлек. Үз-үзеңне әдәпле тоту күнекмәләренә йомгак ясау.

28 нче тема. Мин, син, без.
Балалар коллективында бөтен эшләр бергәләп эшләнгәндә генә җиңел эшләнә.

29 нче тема. Малайлар һәм кызлар арасындагы дуслык турында.
Малайлар һәм кызлар арасында этик нормалар турында сөйләшү. Кызларга һәм малайларга карата таләпләр таблицасы белән эш.

30 нче тема. Башкалардан начар түгел.
Рольле уеннар. Хикмәтле сүзләр белән эш.

31 нче тема. «Үзеңә үзең әйт».
Кешеләргә иң кирәкле 5 әхлак кагыйдәсе язарга. Һәрберсе янына үз-үзеңә билге куярга. Рольле уеннар.

32 нче тема. Үз дәрәҗәңне үзең сакла, кеше!
Түгәрәк өстәл артында сөйләшүләр. Проблеманы хәл итүдә үз фикереңне белдерү, уртак фикергә килә алу. Үз дәрәҗәңне табу өчен юллар билгеләү.

33 -34 нче тема. Этикет – уңышка юл. Әти-әниләр, әби-бабайлар катнашында өйрәнелгән күнекмәләрне күрсәтү өчен театральләштерелгән кичә.

**Тематик планлаштыру**
**4 нче сыйныф**

| **№** | **Тема** | **Сәгатьләр саны** | **Эшчәнлек формасы.** |
|---|---|---|---|
| | **Аралашу этикасы (7сәгать)** | | |
| 1 | Тирә-ягыңа игътибар белән кара. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Педагогик мәсьәләләр чишү. |
| 2 | Үз-үзең була белү осталыгы. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 3 | Гражданинга нәрсә лаек. | 1 | Уен. Танып белү әңгәмәсе. |
| 4 | Хезмәт эш көннәрендә дә бәйрәм ясый ала. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Мәкальләр белән эш. |
| 5 | Мәктәп вальсы бәйрәме. | 1 | Әкияткә сәяхәт. |
| 6 - 7 | Көзге янына чакыру. | 2 | Хикәя. Әңгәмә. Уен. Мультфильмнар карау. |
| | **Этикет (8 сәгать)** | | |
| 8 | Сабыр төбе – сары алтын. | 1 | Әңгәмә. Мәсьәләләр чишү. |
| 9 - | Синең үз-үзеңне тоту стиле. | 2 | Танып белү әңгәмәсе. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | | | Мәкальләр белән эш. Уен. |
| 11 | Малайлар. Кызлар. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 12 | Уйныйбыз һәм уйлыйбыз. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Рольле уеннар. Саф һавада хәрәкәтле уеннар. |
| 13 | Кайчан нинди сүз әйтергә. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 14 | Уртак өстәл артында. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Рольле уеннар. |
| 15 | Киң күңеллелек һәм яхшылык. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. |
| **Әйләнә-тирәдәгеләр белән аралашуның этик нормалары (10 сәгать)** | | | |
| 16 | «Яхшылык кылырга ашык» (халык хикмәте) | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Рольле уеннар. Беренче сыйныф укучыларына бүләк. |
| 17 | «Яхшы уйла, һәм фикерләрең яхшы гамәлләргә әйләнер» (Л.Н. Толстой) | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уеннар. |
| 18 | Әти-әни йорты. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Рольле уеннар. Рәсемнәр конкурсы. |
| 19 | Үз әниләрегезне яратыгыз. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Ситуацияләр уйнап карау. Анкета үткәрү. |
| 20 | «Без әниләребезне котлыйбыз». | 1 | Бәйрәм. |
| 21 | Йөрәген кешеләргә бирүчеләр турында. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Шәһәрнең туган якны өйрәнү музеена экскурсия. |
| 22 | Юмарт була бел. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Рольле уеннар. |
| 23 | Рәхмәт белдерү бәйрәме. | 1 | Бәйрәм. |
| 24 | Кеше яхшы эшләре белән мактаулы. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Шәһәрнең күргәзмә залына бару. |
| **Коллективта аралашу этикасы (9 сәгать)** | | | |
| 25 | Миңа минем турыда сөйлә. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 26 | Бер-берегезгә иътибар белән карагыз. | 1 | Әкияткә сәяхәт. Уен. |
| 27 | Коллективка бүләк. | 1 | Дәрес - сюрприз. |
| 28 | Мин, син, без. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Уен. |
| 29 | Малайлар һәм кызлар арасындагы дуслык турында. | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Таләпләр таблицасы белән эш. |
| 30-31 | Башкалардан начар түгел. | 2 | Танып белү әңгәмәсе. Рольле уеннар. Хикмәтле сүзләр белән эш. |
| 32 | «Үзеңә үзең әйт». | 1 | Танып белү әңгәмәсе. Рольле уеннар. |
| 33 | Үз дәрәҗәңне үзең сакла, кеше! | 1 | Түгәрәк өстәл артында сөйләшү. |

| 34 | Этикет – уңышка юл. | 1 | Бәйрәм. |
|---|---|---|---|

**Йомгаклау өлеше.**

**Ирешелгән нәтиҗәләр.**

Бала чакта барлыкка килгән әхлак нормалары кешене җитлеккән, олыгайган чорына кадәр озата бара. Бары тик  рухи-әхлакый яктан камил шәхес кенә җәмгыятьтә үз урынын табып,  гаиләсе, дуслары, башка кешеләр белән дөрес мөгамәлә урнаштырып, тормышта уңышка ирешә алачак.

**Кулланылган  әдәбият**

**Укытучы өчен**:


1. Казыйханов, В.С. Әхлак дәресләре / В.С.Казыйханов.- Яр Чаллы: 1998. – 240 б.
2. Смирнов, Н.А. Этика и этикет младших школьников: Пособие для учителей и родителей учащихся начальных классов/Н.А.Смирнов.- М.: Школьная пресса, 2002. – 112 с.
3. Савинов Е.С. Стандарт второго поколения. Примерная основная образовательная программа образовательного учреждения. Начальная школа. – М.: Просвещение, 2011.
4. Сухомлинский, В.А. Хрестоматия по этике / В.А. Сухомлинский, О.В. Сухомлинская. – М. : Педагогика, 1990. – 304 с.
5. Татар халык авыз иҗаты. 6 томда. – Казан: Татарстан китап нәшрияты,1988. – 576 б.
6. Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. Мәгърифәт-мәңгелек юлдаш (гыйлем-тәрбия дәресләре) / Хуҗиәхмәтов Ә.Н.- К: ТаРих, 2002.
7. Энциклопедия этикета. – СПб.:Мим-Экспресс, 1996. – 352с.


**Укучыларга:**


1. Н.Исәнбәт . Балалар фольклоры / Н.Исәнбәт. – Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1990. – 487 б.
2. Климанова Л.Ф. Азбука. 2-ая часть / Климанова Л.Ф. – М: Просвещение, 2011.
3. Лихачева, Л.С. Уроки этикета в рассказах, картинках и задачках/  Л. С. Лихачева . – Екатеринбург : Уральское изд-во, 2001 . – 318 с.

4. Т.Шакирова. Тукай иленә сәяхәт-Путешествие в мир Тукая/ Т.Шакирова, Г.Хәйдарова. – Казан: Татар. кит. нәшр.; 2012. – 127 б.
5. Я познаю мир. Детская энциклопедия. Этикет во все времена. М.: издательство: “Астрель”, “Олимп”, “АСТ”, 2000. – 511 с.

**Интернет-ресурслар:**

1. Сайт Министерства образования и науки Республики Татарстан http://mon. tatar. Ru

2. http://www. km. ru – портал компании «Кирилл и Мефодий».

3. Детский портал «Солнышко» http://www. solnet. ee/

4. Законодательство Республики Татарстан http://www. tatarkodeks. ru/

5. Сайт «Учительской газеты» http://www. ug. ru/

**Өстәмәләр**

**1 нче өстәмә**

**Әхлакый тәрбиялелекнең диагностикасы**

Күрсәтмә:

Укытучы балаларга түбәндәге сүзләр белән эндәшә: "Мин сезгә хәзер 10 төрле әйтем укыйм. Игътибар белән тыңлагыз. Уйлагыз, сез алар белән күпмегә килешәсез. Әгәр тулысынча килешәсез икән, җавабыгызны 4 балл белән билгеләгез, килешмәгәнгә караганда килешү яхшырак дип санийсыз икән – 3 балл, аз гына килешәсез икән 2 балл, бөтенләй килешмисез икән – 1 балл куегыз. Балларыгызны сорауның номеры белән янәшә языгыз (1.- 4, 2.- 3....) Әйтемнәрнең һәрберсен игътибар белән тыңлагыз. Уйлагыз, сез алар белән ни дәрәҗәдә килешәсез (алар сезнең турыдамы).

**Сораулар:**

1. Мин еш яшьтәшләремә һәм өлкәннәргә карата мәрхәмәтле булам.
2. Сыйныфташым бәлагә тарса, аңа булышу минем өчен мөһим.
3. Кайбер өлкәннәр белән тотнаксыз булу ярый дип уйлыйм.
4. Үземә ошамаган кешегә тупас булсам да ярый дип уйлыйм.
5. Әдәплелек башка кешеләр арасында үз-үземне тота белергә ярдәм итә дип уйлыйм.
6. Үз адресыма әйтелгән дөрес булмаган шелтәгә дофа итеп сүгенсәм дә ярый.
7. Әгәр класста кемнедер үртиләр икән, мин дә аны үртим.
8. Мин кешеләрне шатландырырга яратам.
9. Кешеләрнең начар гамәлләрен кичерә белергә кирәк дип уйлыйм.
10. Әгәр дә кеше хаклы булмаса да, аны аңлый белергә кирәк дип уйлыйм.

Нәтиҗәләрне эшкәртү:

3, 4, 6, 7 нче номерлар (тискәре җаваплар) түбәндәгечә эшкәртелә:
4 баллга - 1 берәмлек,
3 баллга – 2 берәмлек,
2 баллга - 3 берәмлек,
1 баллга - 4 берәмлек языла.
Ә калган җавапларда нинди балл куелган, шуның кадәр берәмлек өстәлә. 4 баллга - 4 берәмлек, 3 баллга — 3, һ.б.

Нәтиҗәләрне билгеләү:

34 тән 40 ка кадәр берәмлек — үз-үзеңне әхлакый бәяләүнең **югары** дәрәҗәсе.
24-33 - үз-үзеңне әхлакый бәяләүнең **урта** дәрәҗәсе. .
16 - 23 - үз-үзеңне әхлакый бәяләүнең **урта дәрәҗәдән түбән**.
10 - 15 - үз-үзеңне әхлакый бәяләүнең **түбән** дәрәҗәсе.

**Яшәеш байлыкларына карата мөнәсәбәт диагностикасы**.

Күрсәтмә:

"Күз алдыгызга китерегез, сезнең кулыгызда тылсымлы таяк һәм 10 теләк язылган кәгазь. Ә теләкләрнең 5-есен генә сайлап була” (Исемлек тактага языла.)

Теләкләр исемлеге:

1. Барысы да ярата торган кеше булу.
2. Күп акча.
3. Иң яхшы компьютер.
4. Тугры дус.
5. Миңа әти-әниемнең сәламәтлеге мөһим.
6. Башкалар белән командовать итү мөмкинлеге.
7. Бик күп ялчыларың бар һәм алар сина хезмәт итә.
8. Мәрхәмәтле йөрәкле булу.
9. Башкалар өчен кайгыртучан булу һәм аларга булышу.
10. Беркемдә дә беркайчан да булмас әйберне булдыру.

<u>Нәтиҗә:</u>
Тискәре җавапларның номеры: № 2, 3, 6, 7, 10.
Биш уңай җавап – югары  дәрәҗә.
4-3 — уртача дәрәҗә.
2 — уртачадан түбән дәрәҗә.
0-1 — түбән дәрәҗә.

**2 нче өстәмә.**

## Әти-әниләр өчен анкета

## Анкета № 1

1. Балагыз буш вакытында нәрсә белән шөгыльләнә?
2. Нинди уеннарга өстенлек бирә?
3. Нинди төрдәге күңел ачулар ярата?
4. Кем белән ешрак уйный?
5. Башка балалар арасында үзен ничек тота? (актив, пассив, оялчан, агрессив һ.б..)
6. Өйдә нинди йөкләмәләре бар?
7. Өйдә баланы тәрбияләү белән турыдан-туры кем шөгыльләнә: этисе, әнисе, әбисе, бабасы, апасы, абыйсы, башка туганнары?
8. Буш вакытларыгызда  бала белән ялыгызны кайда үткәрәсез: өйдә, прогулкада, театрда, кинода, телевизор каршында, компьютер каршында.
9. Сез балагызның дусларын, аларның әти-әниләрен беләсезме?
10. Балагызның дуслары сезгә кунакка киләме?
11. Бала тәрбияләүдә сезне нәрсә читенсендерә?
12. Тәрбиянең нинди методларын кулай күрәсез? (юмалау, аңлату, катгый таләпләр, җәза, мактау, дустанә сөйләшүләр һ.б.)

## Анкета № 2

1. Сез ничек уйлыйсыз, үзе яшәгән гаиләдән балагыз нәрсә көтә?
А) көнкүрешнең яхшы оештырылган булуын;
Б) аралашу шатлыгын;
В) тынычлык һәм яклау;
2. Гаиләдә сезне иң күбе нәрсә борчый?
А) балаларның сәламәтлеге;
Б) яхшы укуы;
В) балалрның өй хезмәтендә катнашуы;
Г) балаларның кәефе һәм аның нидән үзгәрүе.
3. Балагыз гаиләдә ялгызмы?
А) әйе;
Б) юк;
В) белмим.
4. Сез ничек уйлыйсыз, балагыз булачак гаиләсен әти-әнисенең гаиләсенә ошаган булуын теләр идеме?
А) әйе;
Б) юк;
В) белмим.
5. Балагыз өчен кайсы тормыш күрсәтмәләре иң мөһиме дип уйлыйсыз?
А) материаль яктан тәэмин ителгән булу;
Б) күп дуслары булу.
6. Сезнең балагыз гаиләдәге мораль һәм материаль проблемалар белән танышмы?
А) әйе;
Б) юк;
В) белмим.
7. Балагызның гаиләдән яшерен серләре бармы?
А) әйе;
Б) юк;
В) белмим.
8. Балагыз өчен кичен өйдә булу ул нәрсә?
А) аралашу шатлыгы;
Б) үз-үзең була алу;
В) интегү һәм газап чигү.

**Анкета № 3**

1. Балагызда нинди уңай яклар тәрбияләргә телисез?
2. Нәрсә өчен мактыйсыз, нәрсә өчен җәзалыйсыз?
3. Ничек кызыксындырасыз? Ничек җәза бирәсез?
4. Балагызның характерындагы нинди үзенчәлекләр сезгә ошамый?

**Укучылар өчен анкета**

**Анкета № 1**

1. Синең характерыңның кайсы яклары әти-әниеңә ошый?
2. Сине нәрсә өчен мактыйлар, орышалар, җәза бирәләр?
3. Сине нәрсә һәм нәрсә белән кызыксындыралар?
4. Сиңа нәрсә өчен һәм ничек җәза бирәләр?
5. Синең характерыңның кайсы яклары әти-әниеңә ошамый?
6. Син нәрсә эшләргә яратасың? Синең яраткан шөгылең?

**Анкета № 2**

1. Серләреңне әти-әниеңә сөйлисеңме?
2. Үз тәртибеңне контрольдә тотарга тырышасыңмы?
3. Әти-әниеңнән нинди бүләкләү көтәсең?
4. Гаиләдә кичләрен ничек үткәрергә телисең?
5. Сиңа әти-әниләрең белән аралашу җитәме?
6. Әти-әниләрең синең дусларың белән танышмы?
7. Ничек уйлыйсың, характерыңдагы нинди сыйфатлар өчен сине хөрмәт итәргә була?
8. Характерыңдагы кайсы сыйфатларны үзгәртергә була?